**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.09.2024 № 1068

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларының 2025 елга норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты һәм «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга 2025 елга беркетелгән норматив чыгымнарны расларга;

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең карары белән расланды

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР (муниципаль район исеме)**

| Гомуми белем бирү оешмасының төре һәм төре | Урнашу урыны | Бер тәрбияләнүчегә, елына норматив чыгымнар |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | Шәһәр җирлеге | 118316 |
| | Авыл җирлеге | 119559 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | Шәһәр җирлеге | 177385 |
| | Авыл җирлеге | 181658 |